ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

_______________ г. Казань ______________

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү

2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерам:

1. Бирелгән Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү Тәртибен расларга.
2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы, гомуми бүлек, хокукый эш буенча әйдәп баручы киңәшче һәм Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында коррупцион һәм башка хокук бозуларга профилактика ясау өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
3. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә, хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы мәгълүматларның сакланышы өчен җаваплы.
4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны рәис урынбасары Ю. Б. Матвеевка йөкләргә

Рәис Ф. С. Батков

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының ____ елдан ___ номерлы боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасының Биоресурслар буенча дәүләт комитетына (алга таба - Дәүләт комитетына) кергән, Дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба - хезмәткәрләр), ә шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган һәм Дәүләт комитеты эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы эшчеләр (алга таба - эшчеләр) тарафыннан эшләнгән, коррупция һәм янау фактларын, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысуны, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозуны, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләрне үз эченә алган (алга таба-мөрәҗәгать итү) коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели. Башка затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләрне үз эченә алган мөрәҗәгать, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлеше нигезендә тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Мөрәҗәгать "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яки эшләнгән хокукка каршы эшчәнлек турында, шулай ук әзерли торган, кыла торган яки кылган зат турында мәгълүмат булганда, мөрәҗәгать, аларның компетенциясенә караган хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

3. Хезмәткәргә карата дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хезмәт тикшерүе уздырыла (хезмәткәрдән язмача аңлатма алына).

4. Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән фактлар турында, хезмәт тикшерүен үткәргән Комиссия бәяләмәсе нигезендә, коррупция күренешләре билгеләре булу турында расланган очракта, Дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Дәүләт комитеты комиссиясенә дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тәкъдим кертә. Хезмәткәргә карата тиешле фактлар расланса, аның язма

аңлатмалары анализыннан чыгып, аңа карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча әзерләнә торган, эшләнә торган яки эшләнгән хокукка каршы эшчәнлек турында, шулай ук әзерли торган, кыла торган яки кылган зат турында мәгълүмат булган очракта, туры килүче мәгълүмат аларның компетенциясенә караган хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

5. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга җавапны әзерләү, Дәүләт комитетында коррупция һәм башка хокук бозуларга профилактика алып бару эше өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы, шулай ук Дәүләт комитетының хокукый эш буенча әйдәп баручы киңәшчесе Дәүләт комитетында коррупция һәм башка хокук бозуларга профилактика алып бару эше өчен җаваплы затка, Татарстан Республикасы ведомствоара электрон документлар әйләнешенең бердәм системасы аша, гражданга җавап җибәрү срогы чыкканчы 15 көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать буенча язма тәкъдимнәр җибәрәләр.

6. Әгәр мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупция юнәлешендәге фактлар турында мәгълүматлар булган очракта, соңгысы аны карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карау дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы, шулай ук Дәүләт комитетының хокук эше буенча әйдәп баручы киңәшчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.